| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.04.2020 № 579-п

“2020 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә хуҗалары булган этләрне стерилизацияләү” муниципаль программасын раслау турында

“Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм эпизоотик иминлекнең тотрыклылыгын тәэмин итү һәм Саба муниципаль районы территориясенең тиешле санитар торышын тәэмин итү, киләчәктә күзәтүчесез һәм йортсыз калган этләр санының үсү динамикасын киметү һәм йорт хайваннарын тотуга карата таләпләрне үтәү, ә нәкъ менә хайваннарда теләмәгән нәсел барлыкка килүне булдырмау буенча чаралар күрү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. “2020 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә хуҗалары булган этләрне стерилизацияләү” муниципаль программасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына, чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетын формалаштырганда, Программаны, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финансланырга тиешле муниципаль программалар исемлегенә кертергә тәкъдим итәргә һәм, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетының керем өлеше мөмкинлекләреннән чыгып, Программаны тормышка ашыру өчен финанс чаралары бүлеп бирүне күздә тотарга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р.Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

# “2020 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә хуҗалары булган этләрне стерилизацияләү” муниципаль программасы

**1.** Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2020 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә хуҗалары булган этләрне стеррилизацияләү” программасы |
| Программаның заказ бирүчесе | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләп чыгаручылары | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максатлары | Эпизоотик иминлекнең тотрыклылыгын тәэмин итү һәм Саба муниципаль районы территориясенең тиешле санитар торышын тәэмин итү, күзәтүчесез калган этләрнең санын җайга салуның гуманлы алымнарын куллану, йорт хайваннарын тотуга карата таләпләрне үтәү, ә нәкъ менә хайваннарда теләмәгән нәсел барлыкка килүне булдырмау буенча чаралар күрү. |
| Программаның бурычлары | 1. Этләрне стерилизацияләү;<br>2. Күзәтчесез һәм йортсыз калган этләрнең санын киметү;<br>3. Йорт хайваннарын тотуга карата закон таләпләрен үтәү, ә нәкъ менә этләрдә теләмәгән нәсел барлыкка килүне булдырмау буенча чаралар күрү. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2020 еллар |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2020-2024 елларда Программаны Саба муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауның гомуми күләме 740,000 мең сумны тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2020 ел-740,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме фаразлану характерына ия һәм ТР Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) ТР Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. |
| Көтелгән нәтиҗәләр | Программа чараларын тормышка ашыру киләчәктә күзәтүчесез һәм йортсыз калган хайваннар саны арту мөмкинлеген киметергә ярдәм итәчәк. |

## 2. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика.

Теләсә кайсы торак пунктта һәрвакыт күзәтүчесез һәм йортсыз калган хайваннар санын чикләү белән бәйле проблемалар бар.

Йортсыз этләр – чыгарып ташланган кыргыйга әйләнгән йорт хайваннары яки чыгарып ташланган йорт хайваннарының балалары. Йортсыз этләр - җирлекнең экологик һәм социаль чире, эт хуҗаларының җаваплылыгы киму күрсәткече.

Стерилизация-операция ярдәмендә нәсел булдыру сәләтен бетерү. Стерилизацияләүнең беренче һәм һичшиксез файдасы-йорт хайваннары санын җайга салу. Йорт хайваннары үрчүенә юл куймыйча, без урамда хуҗасыз калган хайваннар санын, кирәкле булмаган йорт хайваннары санын киметәбез. Стерилизацияләүнең икенче файдасы-ул хайванның тормыш сыйфатына һәм озынлыгына уңай йогынты ясый. Стерилизация җитди авыруларны профилактикалау булып тора. Стерилизацияләнгән хайваннар тынычрак булалар.

2020 елның 1 гыйнварына Саба муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнар 1549 эт асрыйлар, шуларның 257 се ана эт. Шул ук вакытта 25 ана эт элегрәк гражданнарның үз инициативасы буенча стерилизацияләнгән булган инде.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Саба муниципаль районы территориясендә 2020 елның 1 гыйнварына 232 ана эт асрала, алар киләчәктә нәсел китерә ала. Тулырак мәгълүмат 1 таблицада урнаштырылган.

Уртача, бер тудырганда эт 3-8 көчек алып кайта. Ләкин көчекләрнең саны эт токымына, зурлыгына, ана эт һәм ата этнең сәламәтлегенә, йөкле вакытта туклану рационына, генетикага һәм башка бик күп факторларга бәйле. (https://www.royalcanin.com/ru/dogs/tips/tips/question-skolko-shchenkov-mozhet-rodit-sobaka). Шулай итеп, уртача бер елда, 5 көчек туса, шуларның 2 се ана эт була, шуннан исәпләп чыгарсаң, бер елда 464 ана эт тууы ачыклана.

“Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсе нигезендә, аларның хуҗалары тарафыннан хайваннарны тотуга карата гомуми таләпләргә хайваннарны тиешенчә тәрбияләүне тәэмин итү һәм хайваннарда теләмәгән нәсел барлыкка килүне булдырмау буенча чаралар күрү кирәк.

1 Таблица

Саба муниципаль районы территориясендә хуҗалары булган этләрнең саны турында мәгълүмат

| Җирлек исеме | Торак пункт исеме | Этләр | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Ана этләр | Шул исәптән стерилизация үткәннәр |
| “Байлар Сабасы ш. т. б.” МБ | Байлар Сабасы | 350 | 67 | 2 |
| | Урта Саба | 19 | 1 | |
| Эзмә | Өтернәс | 7 | 2 | 1 |
| | Иләбәр | 36 | 5 | |
| | Эзмә | 30 | | |
| | Пүкәл | 14 | 4 | |
| | Олыяз | 10 | | |
| Шекше | Шекше | 25 | 4 | 1 |
| | Алан-елга | 25 | 6 | |
| | Сәрдә | 28 | 10 | 1 |
| Явлаштау | Мишәбаш | 10 | 1 | 1 |
| | Явлаштау | 32 | 3 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Сатыш | Сатыш | 75 | 19 | 3 |
| | Аккүл-Бигәнәй | 9 | | 1 |
| | Казанчы Бигәнәй | 12 | | |
| | Мамалай | 21 | 2 | |
| | Чәбки-Саба | 9 | 4 | |
| Мичән | Яңа Мичән | 36 | 6 | |
| | Иске Мичән | 18 | 1 | |
| | Керәнне | 9 | 2 | |
| | Бакшанда | | | |
| Олы Нырты | Олы Нырты | 18 | 1 | 1 |
| | Урта Нырты | 5 | | |
| | Завод Нырты | 8 | 1 | |
| | Чәбия Чүрчи | 9 | 3 | 1 |
| Югары Симет | Югары Симет | 25 | 6 | 1 |
| | Түбән Симет | 10 | 1 | 1 |
| Тимершык | Тимершык | 56 | 10 | |
| | Кызыл Мишә | 10 | | 3 |
| | Көек | 16 | 4 | |
| | Мингәр | 17 | 2 | |
| | Сабай | 1 | | |
| Юлбат | Юлбат | 31 | 11 | 5 |
| | Йосыф-алан | 6 | | |
| | Калатау | 10 | 1 | |
| | Тенеки | 9 | 2 | |
| Түбән Шытсу | Түбән Шытсу | 18 | 2 | |
| | Югары Шытсу | 21 | 3 | |
| | Елыш | 12 | | |
| Килдебәк | Мәртен | 2 | 1 | |
| | Килдебәк | 20 | 6 | 1 |
| | Туктар | 18 | 2 | |
| Мишә | Сабабаш | 31 | 4 | 1 |
| | Лесхоз | 65 | 12 | 1 |
| Олы Шыңар | Кече Шыңар | 21 | 1 | |
| | Олы Шыңар | 25 | 4 | |
| | Чулпыч | 2 | 1 | |
| | Тулушка | 2 | | |
| | Оет | 14 | | |
| Курсабаш | Курсабаш | 12 | 1 | |
| | Сүлә | 2 | | |
| | Түбән Утар | 24 | 3 | |
| | Югары Утар | 9 | | |
| | Мөндеш тимер юл аерылышы | | | |
| Шәмәрдән | Мичәнбаш | 6 | | |
| | Кырбаш | 1 | | |
| | Шәмәрдән | 48 | 14 | |
| Иштуган | Иштуган тимер юл аерылышы | 43 | 6 | |
| Иске Икшермә | Өч-Нарат | 11 | 2 | |
| | Татар Икшермәсе | 17 | 1 | |
| | Иске Икшермә | 13 | 5 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Олы Кибәче | Олы Кибәче | 26 | 2 | |
| | Кече Кибәче | 17 | 1 | |
| | Төбәк | 17 | 1 | |
| Арташ | Ике Басу Арташ | 20 | 2 | |
| | Олы Арташ | 19 | 2 | |
| | Язлы-Арташ | 7 | 2 | |
| **Барлыгы** | | **1549** | **257** | **25** |

## 3. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, көтелгән ахыргы нәтиҗәләрне һәм аны тормышка ашыру срокларын тасвирлау.

Эпизоотик иминлекнең тотрыклылыгын тәэмин итү һәм Саба муниципаль районы территориясенең тиешле санитар торышын тәэмин итү, күзәтүчесез калган этләрнең санын җайга салуның гуманлы алымнарын куллану, йорт хайваннарын тотуга карата таләпләрне үтәү, ә нәкъ менә хайваннарда теләмәгән нәсел барлыкка килүне булдырмау буенча чаралар күрү.

Әлеге максатларга ирешү өчен, хуҗалары булган этләрне стерилизацияләү кебек бурычларны хәл итәргә кирәк.

Программа 2020 елда тормышка ашырыла.

## 4. Программаны тормышка ашыру механизмы.

Программаның максатларына ирешү һәм бурычларын тормышка ашыру программага кушымтада каралган чараларны үтәү юлы белән башкарылачак. Чараны үткәрү гражданнарга хезмәт күрсәтү килешүе һәм акты белән раслана.

## 5. Программаны ресурслар белән тәэмин итү.

2020 елда программаны Саба муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауның гомуми күләме 740,000 мең сумны тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча: 2020 елга – 740,000 мең сум.

Программаны финанслау күләме фаразлану характерына ия һәм ТР Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) ТР Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк.

“2020 елда Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
территориясендә йорт хайваннарын
стерилизацияләү” муниципаль
программасына 1 кушымта

## Программаны тормышка ашыру буенча чаралар

| № п/п | Исеме | Үтәү вакыты | Финанслау чыганагы | Еллар буенча финанслау күләме, мең сум. |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | 2020 |
| 1. | Саба муниципаль районы территориясендә хуҗалары булган этләрне стерилизацияләү буенча чаралар үткәрү | 2020 ел | Саба муниципаль районы бюджеты | 740,000 |
| | **БАРЛЫГЫ:** | **740,000** | | |